Әдәби сәхифә

# Йонлач

Камил Җиһаншин

(хикәя)



Илле җиде яшьтә булуга карамастан, шактый яшь күренгән Федор Дементьевич – авыл халкы арасында таралган кушаматы буенча Көрәк кул, күтәрмәнең яңа ышкыланган киң такталарына көчле аяклары белән нык басып, инде ничәнче тапкыр киявенең яңа йортындагы матур итеп сырлап ясалган тәрәзә яңакларын карый.

Шулчак ишек шыгырдап ачылды, һәм аннан, шаркылдап, бар яклап та әтисенә охшаган тыгыз тәнле кызы Наталья белән озын буйлы, чандыр кияве килеп чыкты.

– Әти, ташла инде шул тәмәкеңне. Керик, туңарсың, – дип кычкырды ул.

– Миңа китәргә вакыт, Натаха, – диде Көрәк кул, болыт арасыннан күзен кыскан куе кызыл кояшка ымлап. Һәм бераз таптанып торгач, баскыч буйлап ашыкмый гына әлегә кул җитмәгән, каралмаган ишек алдына төште.

– Йонлач! – дип этенә әмер бирде дә, өшүдән сабырсызланып тыпырчынган Турыкае янына юнәлде. Иркәләп сыртыннан сыйпады. Дилбегәсен ныгытты. Чанадагы печәнне кабартып салды. Толыбына төренеп, брезент белән капланган тыгыз он капчыгына терәлеп утырды.

– Исәнлеккә! Безгә дә килеп чыгыгыз, – дип кычкырды ул артына әйләнеп.

Туктаусыз аяк астында уралган йөнтәс маэмай шыгырдап кузгалып киткән чана артыннан ыргылды һәм күз ачып йомганчы юыртып барган алашаны узып китте. Посёлокны һәм наратлыкны үтеп каен катыш усак урманына килеп керделәр. Кояш агач башлары белән сырланган калкулык артына посты. Караңгы төште.

– Шулай да август аенда өй котларга бармый дөрес эшләдем, – дип уйлады Көрәк кул. – Вакытны сузсам суздым, аның каравы, ике көймәнең койрыгын тоттым: балаларда кунак булдым, итне дә саттым. Шулай да, баш үземдә, – сакалын сыпырып, үз-үзеннән канәгать төстә елмайды.

Юл тау түбән төшеп китте һәм бормаланып чокыр-чакырлы инеш үзәне буйлап сузылды. Чокыр-чакырларда чана, бишектәй, чайкалып-чайкалып ала. Көрәк кул, дилбегәсен кулыннан ычкындырмыйча, сузылып ятты һәм канәгать төстә сатудан кергән акчасын ничек тотыну хакында уйланды.

Акча эшли белмәгән кешеләрне яратмый ул. “Ялкау, бушкуык”, – ди андыйлар турында. Кияүне әйтер идем инде! Бораулаучылар мастеры имеш! Хәтта бер капчык цемент ташлап китәлми... Намуслы! Тьфү! – дип төкерде ул.

Турыкайның куркып пошкырыныуы уйларын бүлде.

Ат колакларын шомырайтты, борын тишекләрен киңәйтеп, тагын пошкырды. Алдан йөгергән Йонлач чанага елышты. Көрәк кул артка күз салып, тирә-якны айкады һәм калкулыкта ниндидер хәрәкәт барлыгын шәйләде. Шомлы шәүләләр сырт буйлап, яшеренмичә, ачыктан-ачык шуышалар иде. Бүреләр!!!

Бармаклары әрнеп-авыртып куйды, калак сөяге турында нәрсәдер чәнчеп алды.

– Әйдә! Атла! – дип гыжылдады Көрәк кул, алашасын бар көченә камчылап. Хәер, малкай болай да бар көченә чапкан җайга койрыкялын сикертеп, такыр юлдан ыргыды: колакта җил уйнады. Караңгылыктан килеп чыккан агачлар шунда ук артта калды. Җигүле ат артыннан кар бураны күтәрелде.

Бүре өере караңгыда югалды. Инеш буйлап барган юл, элмәк ясап, биек, озын калкулыкны урап үтә. Тирә-яктагы һәр үләнне белгән карт башлык шул калкулыкны ашыкмый гына кистереп, өерен чана юлына, Турыкай бар көченә чапкан урынга алып чыкты.

Көрәк кул атын камчылаган уңайга калтыранып, ни эшләргә кирәклеген чамалады: бүре өереннән җиңел генә котылырмын димә. Ул элмәктә хәвеф янавын аңлады, тик кире борылырга соң иде инде – авылдан ерак китәргә өлгерде.

– Бәлки, өлгерермен, – дип үзен-үзе тынычландырды Көрәк кул һәм, дилбегәсен бер кулы белән тоткан килеш, икенче кулы белән печән астындагы балтасын кармалап алды.

Алаша көтмәгәндә кыргый тавыш чыгарып, читкә ыргылды – җигүле ат каршысына ук кебек атылып бүре өере килеп чыкты. Гайрәтле башлык чабып килешли Турыкайның муенына сикерде. Тик ерткыч сикергән уңайга күкрәгә белән тәртәгә килеп бәрелде һәм кар өстенә очып барып төште, югыйсә малкай бер мизгелдән богазы өзгәләнеп җиргә авасы иде. Көрәк кул аңына килеп, он капчыгын эләктерде дә, аны бар көченә өер өстенә томырды.

Авыр капчык төшергә дә өлгермәде, бүреләр тере дулкын булып аны эләктереп алды һәм ак болыттай туздырып та ташлады. Ул арада Көрәк кул чананы юлга борырга өлгерде.

– Әйдә! Әйдә! – дип буылып акырына-акырына, алашасын аяусыз камчылады. Куркудан һәм авыртудан шашар чиккә җиткән Турыкай, тояк астыннан кисәк-кисәк кар чәчрәтеп, алга җилде.

Ул алга йөгергән Йонлачны узып китте.

– Әллә ычкындыкмы? – дигән өмет чаткысы үтте башыннан.

Чана чайкала-чайкала чокыр-чакырлар буйлап җилде. Борылмаларда Көрәк кул әле бер, әле икенче якка авышты. Ә арттан ач бүре өере бастырды. Көрәк кул моны тәненең һәр күзәнәге белән тойды. Карт бүре, тешләрен куркыныч шыкырдатып, чана артыннан өлгерәлмәгән Йонлачны эләктерергә тырышып карады, ләкин маэмай, үлем янавын аңлап, тизлеген арттырды, соңгы көчен җыеп чанага сикерде.

Тар юл буйлап сузылган бүре өере шундый иркен, җиңел чаба ки, әйтерсең лә, хәлдән тайган атны бастырып, кар өстеннән шуышып йөзеп килә.

Көрәк кул аларның өзек-өзек тын алышын тойды хәтта. Тагын бераздан бүреләр, каннары кызудан әсәрләнеп, күптән көткән табышын өзгәләп ташлаячак. Сарык тиресеннән тегелгән толыпны астыннан тартып алып, юлга ыргытты. Ерткычлар бер мәлгә генә туктап калды, тик алдануларын аңлап, тагын да ярсыбрак чаба башлады.

Көрәк кул бүре өере өстенә я колакчын бүреген, я бияләйләрен ташлап карады, ләкин бер тапкыр алданган сорылар бу әйберләргә игътибар итмәде. Эзәрлеклүдән кызган өер, канга сусап, алга җилде, ара якынайганнан-якынайды. Шашындыргыч, хәлдән тайдыргыч узыш коточкыч финалына якынлаша иде.

Куркудан коты очкан Федор Дементьевич, тәкрекләрен чәчә-чәчә, бертуктаусыз үкерде: “Тизрәк, Турыкай, тизрәк!” – дип атын куалады, артына борылып, бүре өеренә балтасы белән янады: “Тураклыйм! Барыгызны да тураклыйм!”

Берничә секундтан карт бүре кулына килеп ябышыр, калган өчесе аны тере килеш өзгәләргә тотыныр кебек иде...

Ир калтыранып як-ягына каранды. Аякларына сарыган Йонлачка күзе төште.

Көрәк кулның күзләрендә иблис уты ялтырап китте – маэмай? Тере җанвар, кан – өергә менә нәрсә кирәк! Ул маэмайны аягы белән үлемгә таба этте, тик бахыркай, тәпиләрен аерып басып, чанага эләгеп калды. Аның бөтен булмышында гаҗизлек һәм рәнҗү сизелде.

– Бар, юньсез, – ярсыган Көрәк кул этәч тавышлары чыгарып чырылдады һәм итеге белән маэмайга саллы гына кундырды.

Йөнтәс янтайды, яңакларын кысып, соңгы көченә чана читенә ябышты.

Бүреләр якынлашты. Көрәк кул аркасын чана алдына терәп, бар көченә аягы белән киң маңгайлы башка китереп типте: маэмай, шома итеп ялтыратылган агачта казык тешләреннән аксыл буразналар калдырып, чанадан кыйгаеп очты һәм, һавада мәтәлчек атып, юлга килеп төште. Йөрәк өзгеч чәрелдәү, тонык үкерү тавышлары колакны ярды.

“Бетте!” – дип уйлап куйды Көрәк кул, калтыранып. Әммә этенең үзенә текәлгән рәнҗүле карашы күз алдыннан китмәде.

Җигүле чана зиреклекне җилеп үтте һәм уйсулыктан кар баскан калкулыкка борылды, әнә авылның сирәк-мирәк утлары да шәйләнә. Йончыган Турыкай адымын әкренәйтте.

Шунда гына яртылаш чишенгән Көрәк кул куркудан һәм салкыннан бөтен тәне калтыравын тойды. Печән белән капланып, өстенә брезент кисәген тартып япты һәм ераклашканнан-ераклаша барган карурманга сагаеп күз салгалады. Курку хисе үтте, тәпкәрәк чигенгәндәй тоелды. Ләкин әлеге вакыйганы хәтереннән кат-кат барлап, Көрәк кул әледән-әле бәрешеп куйды.

Авыл башына якынлашкач, ул йончыган атын бераз тыя төште. “Шәп тә инде минем бахбай. Башка ат мондый узышка чыдамас иде.”

Буш, күңелсез урам буйлап үзенең тоташтан коелган койма артында утырган матур йортына якынлашкач, күңеле тулып китте: “Бүтән күрә алмавым да бар иде ич.”

Тәрәзә капкачлары тыгызлап ябылган. Ут алмаганнар.

– Йоклый, шайтан. Аңа нәрсә, – дип сукранды Көрәк кул. Капканы ачып керде дә, итеге белән ишеккә типте.

Өйдә ыгы-зыгы сизелде. Ашыгып атлаган аяк тавышлары ишетелде. Келә шалтырады. Ишек ачылды һәм Көрәк кул, ябык сына күз дә салмыйча, өйалдына үтте. Ут кабызгычка басты – караңгы.

– Лампочка янып чыкты, Федя, – дип тыныч кына аңлатты хатыны. Көрәк кул сүгенде дә, эссе итеп ягылган аш өенең ситсы чаршавы артына кереп югалды.

– Тиз кайтырсың дип уйламаган идем. Иртәгә генә көттем, – дип акланды хуҗабикә.

– Аш-суыңны кара, туңдым, – дип боерды ир, урындыкка чүгеп. – Шайтан алгыры, Турыкай урамда бит, – дип, иске бүреген эләктереп чыгып йөгерде.

Алашасын тугарып, җылы абзарга кертте. Дерелдәп торган янбашларына чыпта япты. Утлыкка бер кочак хуш исле печән салды.

– Аша. Бу сиңа игелекле хезмәтең өчен, – Көрәк кул атның ялын сыйпарга дип кулын сузган иде, алаша ни өчендер башын читкә алды.

– Син нәрсә?.. Нәрсә булды?.. Юкка үпкәлисең! Йонлач булмаса, без барыбыз да һәлак булыр идек. Аңлыйсыңмы – барыбыз да! Ә мин сине коткардым... Коткардым! – дип акланып пышылдады Көрәк кул. Турыкай, авыр сулап, читкә караган килеш торуын дәвам итте.

“Кем белә, үлмәгән дә булыр идек, бәлки? – кинәт Көрәк кулны кемдер шулай әчтән фашлады. – Берсенә балта белән тондырсаң, калганнарына сабак булыр, бәлки, егылган иптәшләренә дә ташланырлар иде.”

Шушы гади генә фикердән Федор Дементьевичның күңеле төште. “Бөтенләй җебедем. Ни дип үземнең башымны катырам... Үткән эшкә салават...”

Эт оясы янынан үтеп барганда, чылбырга абынды. Аның җанны өтеп шалтырап куюыннан йөрәген каты авырту телеп үтте. Кинәт билен алган хәлсезлеген җиңеп, ул өенә кереп китте.

Хатыны өстәл әзерләп көтеп тора иде. Алгы якта юынып, түргә үтте, аркасын җылы мичкә терәде дә тынып калды.

– Юлың уңдымы, Федя? Балаларны очраттыңмы соң?

– Очраттым... Исән-саулар. Өйләре зур, бөтен уңайлыклары бар. Газ ягып җылыталар. Бер атнага кайтырга җыеналар... Ихата-курада эш җитәрлек.

– Аларның үз өйләрендә дә эш бетмәгән хәзер, – дип кыюсыз гына әйтеп куйды хатыны.

– Ярар, үзләрендә дә өлгерерләр...

– Итеңне саталдыңмы?

– Әлбәттә! Ит торма түгел, бер сызгыру җитә, – Көрәк кул ымсындыргыч калын төенчекне капшады да, бүләген исенә төшереп, икенче кесәсеннән төргәк чыгарды.

– Мә, – дип чәчкәле яулыкны җәеп җибәрде.

– И, рәхмәт инде, Федя! Рәхмәт!.. Бигрәк матур!

– Куп сөйлисең, – дип, Көрәк кул кырт кисте һәм шапыр-шопыр кәбестә шулпасын чөмерүен дәвам итте.

Көзге каршында яңа яулыгын бөркәнеп карагач, хатын тагын да җанлана төште. Иреннәренә кыюсыз гына елмаю кунды. Өстәлне җыештырганда, әйтеп куйды:

– Сөякләрне Йонлачка чыгарып керим әле.

Көрәк кул чак чәчәмәде.

– Ят, үзем бирермен. Барыбер тартырга чыгасым бар, – дип каршы төште ул. – Турыкайны да эчерергә вакыт.

Савытны алып, саф һавага чыкты. Тәмәкесен тартты. Атын эчерде. Тагын тәмәке кабызды. Башыннан үткән вакыйганы чираттагы тапкыр барлап, чарасызлыктан үзен күпме генә акларга тырышып карамасын, Йонлачның үлеме, шырпыдай, Көрәк кулның миенә кадалды, чәнчеп-чәнчеп алды.

Көрәк кул яткач та җанына урын табалмады. Аның күз алдында һаман бер күренеш: кар бураны аша кара шәүлә очып бара, һавада әкрен генә әйләнеп, ач, ярсыган өер арасына төшеп югала. Очып бара, әйләнә һәм янә...

Тыштан вакыт-вакыт сәер, аңлаешсыз тавышлар ишетелде. Ул, шуларны тыңлап, үзе дә сизмәстән оеп йокыга талды. Менә тагын өер аны куып җиткән, чолгап алган, тере элмәк һаман ныграк кысыла. Башында көчәя барган үлем гөрелтесе ишетелә. А...а...а...! – Көрәк кул үз тавышыннан куркып уянды.

– Федя, нәрсә булды? Авырыйсыңмы әллә? – дип иңбашына кагылды хатыны.

Көрәк кул аңа гаҗәпләнеп текәлде – кайда икәнен төшенә алмады – һаман күргән төшен уйлады. Як-ягына карангач, ниһаять, өен һәм хатынын таныды.

– Я, Хода, – дип җиңел сулап куйды.

– Ник шул тиклем кычкырдың, Федя? – дип сорады коты алынган хатыны.

– Итне күбрәк ашаганмындыр, күрәсең. Күңел болгана. Пешерүең җитмәгән... Йокла...

Хатын иренең чал бөдрәләрен сыйпый башлады. Кечкенә каты учын башына куйган килеш йоклап та китте. Көрәк кул аны сак кына мендәргә алып салды. Йокысы качты. Ул онытылырга, күңеллерәк әйберләр турында уйларга тырышып карады, тик Йонлач турындагы уйлар тагын да әрсезләнебрәк басты.

Әрнеп, сагышланып, әле кушаматы да булмаган көчекне өенә алып кайтуын исенә төшерде. Шундый көчле, читләрне якын җибәрмәгән йорт сакчысы үсүенә сөенеп бетәлмәгән иде. Эштән каршы алганда шатланып ләңгелдәвен, очынып, ыргып сикерүен, тугры күзләрен күз алдына китерде – ул хуҗасының бөтен теләкләрен үтәргә әзер иде.

Иртәнгә тиклем борсаланып яткач, Көрәк кул сак кына торып киенде дә, ишегалдына чыкты. Ишекне ачты.

Күтәрмә буенда иртәнге эңгер-меңгердә бер шәүлә пәйда булды: борыны теткәләнгән, тире кисәкләре салынган, колагы кимерчәккә чак эләгеп торган, йоны кисәк-кисәк булып укмашкан, тешләре ыржайган.

– Йонлач?! Синме әллә?! Ышанмыйм...

Югалып калган Көрәк кул чайкалып китте, ирексездән бусагага абынып егылды...

Башында яңадан көчәя баручы үлем гөрелтесе ишетелде...

***Уфа, май, 1986 ел.***

*Р.һәм Л. Мөхәмиевалар тәрҗемәсе (Нөркәй мәктәбе).*

